Республика Татарстан
Новоимянское сельское поселение Сармановского муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районынын Яңа Имән авыл жирлеге

---

КАРАР
22 .08.2024 ел

КАРАР
№ 12

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Башкарма комитетының 2015 елның 28 декабрендәге «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 15 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гараж берләшмәләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 24 июлендәге 338-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 2 пункты, Сарман муниципаль районының «Яңа Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Имән авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Башкарма комитетының 2015 елның 28 декабрендәге «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 15 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаның 11 пунктына ", яисә физик затларга мондый җир кишәрлеге әлеге кодекс гамәлгә кертелгән көнгә кадәр бирелгән булса һәм бу чакта мондый җир кишәрлеге хосусый милектә була алмаса, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануда, гомерлек мирас итеп биләүдә " сүзләрен өстәргә.

2. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә әлеге карарны игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Имән авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Р.Ф.Гәрәев